СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы КАРАРЫ**

**“22” март 2024 ел** **№ 5**

**“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыенының беренче этабын Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыенының икенче этабын Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт адресы буенча 2024 елның 06 апрелендә 19 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Базар, Совхоз, Гагарин урамнарында яшәүчеләр.

2нче этап: Совет, Тукай, Ленин, Бакча урамнарында яшәүчеләр.

4. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 16

ноябрендәге 5 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Апаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Гагарин, Базар, Совхоз урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю; Гагарин урамының 26 йортыннан 30 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Апаз авылында су челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (авылны төзекләндерү җиһазлары өчен запас частьләр сатып алу (бензин чапкычы, бензин пычкысы); МТЗ 82 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма); “Сабантуй” милли бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (материаллар алу))?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

5. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең Апаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт, Совет урамы, 22А йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов